ГОСУДАРСТВЕННАЯ
ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

420111, г.Казань, ул.Б.Красная, 15/9
тел. 236-91-44, E-mail: tatgi@tatar.ru

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ
ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ

420111, Казан шәһәре, Б.Красная ур., 15/9
тел. 236-91-44, E-mail: tatgi@tatar.ru

П Р И К А З № 149 Б О Е Р Ы К

«31» 10 2013 г.

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре турында, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыруы турында

"Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында"гы 27.07.2004 ел, 79-ФЗ номерлы Федераль законның 20 һәм 20.1 статьялары (02.07.2013 ел үзгәрешләре белән), "Коррупциягә каршы тору турында"гы 25.12.2008 ел, 273-ФЗ номерлы Федераль закон (30.09.2013 ел үзгәрешләре белән), "Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәте турында"гы 16.01.2003 ел, 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17 һәм 17.1 статьялары (29.03.2013 ел үзгәрешләре белән) нигезендә, Россия Федерациясе Президентының 2009 елның 18 маеннан "Федераль дәүләт граждан хезмәтендәге вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның, һәм федераль дәүләт хезмәткәрләренең керемнәре, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрне тапшыруы турында" гы 559 номерлы Указын исәпкә алып, **БОЕРЫК БИРӘМ**:

1. Расларга:

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясендәге Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне тапшыруы турындагы Нигезләмәне (1 нче кушымта);

Инспекциядәге, аларга билгеләнгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, һәм шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә тапшыру мәҗбүри булган һәм шулай ук аларны

биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, һәм шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә тапшыру мәҗбүри булган дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының Исемлеген ( 2 нче кушымта).

2. Шуны расларга:

югарыда күрсәтелгән исемлеккә кертелгән дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданин, дәүләт хезмәтеннән куылганнан соң ике ел дәвамында хезмәт килешүе шартларында оешмадагы вазыйфага куелу һәм (яки) әлеге оешмада ай дәвамында граждан-хокукый килешүе (граждан-хокукый килешүләре) шартларында йөз мең сумнан артык бәяләнүче эшләрне башкару (әлеге оешмада хезмәтләр күрсәтү) хокукына ия, әгәр әлеге оешманың дәүләт, (административ) идарәсенең аерым функцияләре дәүләт граждан хезмәткәренең вәкаләт (хезмәт) бурычларына кергән булса, Инспекциядәге дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибен һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләүгә карата таләпләрнең үтәлеше буенча тиешле комиссиянең ризалыгы белән (алга таба – Комиссия);

гражданинның хезмәт килешүе шартларында оешмада вазыйфа биләвенә һәм (яки) әлеге оешмада граждан-хокукый килешү шартларында эшләр башкаруына (бу оешмага хезмәтләр күрсәтүенә) рөхсәт бирүе турындагы язмача мөрәҗәгатен, комиссия мондый мөрәҗәгать кабул ителгән көннән башлап җиде көн эчендә, Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары белән билгеләнүче тәртиптә карарга һәм кабул иткән карары турында гражданинга бер эш көне дәвамында язмача җавап юлларга һәм өч эш көне дәвамында аны телдән мәгълүматлаштырырга тиеш;

исемлеккә кертелгән дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларына куелган гражданин, дәүләт граждан хезмәтеннән куылганнан соң ике ел дәвамында 2 нче пунктның 2 нче абзацында күрсәтелгән эшләрне башкаруга (хезмәтләрне күрсәтүгә) карата хезмәт яисә граждан-хокукый килешүен төзегәндә яллаучы вәкиленә (эшкә алучыга) үзенең соңгы хезмәт урыны турындагы белешмәләрне хәбәр итәргә тиеш;

югарыда күрсәтелгән исемлек буенча дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче гражданинның, дәүләт хезмәтеннән куылгач, 2 нче пунктның 4 нче абзацында күрсәтелгән таләпләрне үтәмәве, 2 нче пунктның 2 нче абзацында күрсәтелгән әлеге гражданин белән төзелгән хезмәт килешүенең яисә эшләрне башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) граждан-хокукый килешүенең таркалуына китерә;

югарыда күрсәтелгән исемлек буенча дәүләт хезмәте вәкаләтләрен биләгән гражданин белән, ул дәүләт хезмәтеннән куылганнан соң ике ел дәвамында, 2 нче пунктның 2 нче бүлегендә күрсәтелгән хезмәт килешүен яисә эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) граждан-хокукый килешүне төзегәндә, эш бирүче ункөнлек вакыт эчендә аның соңгы хезмәт урынындагы дәүләт хезмәткәрен яллаучыга (эш бирүчесенә) мондый килешүнең төзелүе турында Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары белән билгеләнгән тәртиптә хәбәр итәргә тиеш;

эш бирүченең 2 нче пунктның 6 нчы абзацында билгеләнгән йөкләмәләрне башкармавы хокук бозу булып санала һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылылыкка тартуга этәрә;

гражданинның, 2 нче пунктның 2 абзацында күрсәтелгән, оешмада хезмәт килешүе шартларында вазыйфа биләвен һәм (яки), әгәр дә әлеге оешмадагы

дәүләт идарәсенең аерым функцияләре граждан хезмәткәренең вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, әлеге оешмада граждан-хокукый килешүе (граждан-хокукый килешүләре) шартларында эшләр башкаруын (әлеге оешмага хезмәтләр күрсәтүен) тыюны федераль законнарда каралган очракларда үтәвен һәм эш бирүченең мондый гражданин белән хезмәт килешүен төзү кагыйдәләрен яки граждан-хокукый килешү төзү кагыйдәләрен үтәвен тикшерү Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары белән билгеләнүче тәртиптә башкарыла.

3. 06.09.2010 ел, 53 номерлы, 22.04.2013 ел, № 46/1 номерлы, 13.05.2013 ел, 57 номерлы, 02.08.2013 ел, 101 номерлы боерыкларны көчен югалткан дип табарга.

4. Кадрлар бүлеге башлыгына (И.Н. Никитинага) Инспекциянең барлык дәүләт хезмәткәрләрен дә әлеге боерык белән таныштырып чыгарга.

5. Хокукый идарәнең юридик бүлеге башлыгына (Н.Н. Воронскаяга) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына теркәү өчен юлларга.

6. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башлык** **Крайнов С. А.**

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе боерыгына
1 нче кушымта
«31» 10 20 17 ел.
№149

**Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләрәмәләре турындагы, шулай ук Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясендәге Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрне тапшыруы хакындагы Нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә белән түбәндәгеләрне тапшыру тәртибе билгеләнә:

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә (алга таба - Инспекция) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын (алга таба – граждан хезмәте вазыйфалары) биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан алган керемнәре, милек хокукы нигезендә аларныкы булган милек турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрне, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, милек хокукында аларныкы булган милек турында һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре (алга таба – керемнәр турында, милек турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр) турындагы белешмәләрне;

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары турында, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрне, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре (алга таба – керемнәр, чыгымнар турында, милек һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләр) турындагы белешмәләрне.

2. Дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы гражданинның (алга таба - гражданин) керемнәре турында, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрне тапшыру бурычы, шулай ук Инспекциядәге Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең (алга таба – граждан хезмәткәре) керемнәре, чыгымнары турында, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрне тапшыру бурычы аларга Инспекциядәге гражданин тарафыннан биләүгә дәгъва кылынучы яисә граждан хезмәткәре биләгән граждан хезмәте вазыйфасы Инспекция башлыгы тарафыннан билгеләнүче граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә (алга таба – Вазыйфалар исемлеге) кертелгән очракта йөкләнә.

3. Керемнәр турындагы, милек һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләр гражданнар тарафыннан алар Вазыйфалар исемлегендә каралган граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләнгәндә расланган белешмә формалары буенча тапшырыла.

4. Керемнәр, чыгымнар турындагы, милек һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләр Вазыйфалар исемлегендә каралган граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче граждан хезмәткәрләре тарафыннан, расланган белешмә формалары белән, ел саен хисап елы артыннан килүче киләсе елның 30 нчы апреленнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

5. Граждан хезмәте вазыйфасына билгеләнгәндә гражданин түбәндәгеләрне тапшыра:

а) үзенең граждан хезмәте вазыйфасын биләүгә документлар тапшыру елы артында калган календарь елы өчен барлык чыганаклардан (элеккеге эш урыны буенча керемнәрен яисә сайланган вазыйфасын башкару урыны буенча керемнәрен, пенсиясен, пособияләрен, башка түләүләрен дә кертеп) алынган керемнәре турында белешмә, шулай ук милек хокукы нигезендә аныкы булган милек турында һәм үзенең граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен документарны тапшырган айның артында калучы айның беренче көненә (хисап көненә) мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрне;

б) граждан хезмәте вазыйфасын биләүгә документлар тапшыру елы артында калган календарь елы өчен хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының барлык чыганаклардан (хезмәт хакын, пенсиясен, пособияләрен, башка түләүләрен дә кертеп) алынган керемнәре турындагы белешмәләрне, шулай ук милек хокукы нигезендә аларныкы саналган милек турындагы һәм граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен документарны тапшырган айның артында калучы айның беренче көненә (хисап көненә) мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрне.

6. Граждан хезмәткәре ел саен түбәндәгеләрне тапшыра:

а) хисап периодында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) барлык чыганаклардан (акчалата тәэмин итүне, пенсияне, пособияләрне, башка түләүләрне дә кертеп) алынган үз керемнәре турындагы белешмәләрне, шулай ук милек хокукы нигезендә аныкы булган милек турындагы һәм хисап периодының ахырына булган үзенең мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрне;

б) хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының хисап периодында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) барлык чыганаклардан (хезмәт хакын, пенсияне, пособияләрне, башка түләүләрне дә исәпкә алып) алынган керемнәре турындагы белешмәләрне, шулай ук милек хокукы нигезендә аларныкы булган милек һәм хисап периоды ахырына булган мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрне;

в) хисап елында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) сатып алынган җир кишәрлегенең, күчемсез милекнең башка объектының, транспорт чарасының, кыйммәтле кәгазьләрнең, акцияләрнең (катнашу өлешләренең, оешмаларның устав капиталындагы (склад итеп тотылучы) пайларының) һәр килешүе буенча тотылган үз чыгымнары, шулай ук , әгәр дә килешүнең суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең), килешүне төзүнең алдагы өч елындагы гомуми керемнәреннән артып китсә, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган

балаларының чыгымнары турындагы һәм килешү төзүгә тотылган акчаларның алынган чыганаклары турындагы белешмәләрне (Кушымта).

7. Әлеге Нигезләмәнең 5 нче һәм 6 нчы пунктларында каралган белешмәләр Инспекция башлыгы исеменә кадрлар бүлегенә тапшырыла.

8. Әгәр дә гражданин яисә граждан хезмәткәре үзләре тарафыннан Инспекциянең кадрлар бүлегенә тапшырылган белешмәләрдә кайсы да булса белешмәләрнең чагылмавын яисә тулы күләмдә чагылмавын, яисә хаталар булуын ачыкласа, алар әлеге Нигезләмәдә каралган тәртиптә җентекләнгән белешмәләрне тапшырырга хокуклы.

Граждан хезмәткәре җентекләнгән белешмәләрне әлеге Нигезләмәнең 4 нче пунктында күрсәтелгән вакыт беткәннән соң өч ай дәвамында тапшыра ала.

9. Объектив сәбәпләр аркасында граждан хезмәткәре тарафыннан хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләр тапшырылмаган очракта, әлеге факт Инспекциядәге дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибен һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләүгә карата таләпләрнең үтәлеше буенча тиешле комиссиянең каравына тиешле.

10. Әлеге Нигезләмә нигезендә гражданин һәм граждан хезмәткәре тарафыннан тапшырылучы белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү законнар нигезендә тормышка ашырыла.

11. Әлеге Нигезләмә нигезендә гражданин һәм граждан хезмәткәре тарафыннан тапшырылучы белешмәләр конфиденциаль характерга ия, әгәр дә алар федераль закон белән дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләргә карамаса.

Әлеге белешмәләр Инспекция башлыгына һәм Инспекциянең граждан хезмәткәрләрен вазыйфага билгеләү һәм вазыйфадан азат итү вәкаләтләре белән вәкаләтләнгән башка вазыйфаи затларына, шулай ук федераль законнарда каралган очракларда, башка вазыйфаи затларга тапшырыла.

12. Граждан хезмәткәренең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмә, шулай ук, әгәр дә килешүнең суммасы граждан хезмәтен биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) килешүне төзегән көннең алдагы өч елындагы гомуми керемнәреннән артып китсә, җир кишәрлеген, күчемсез милекнең башка объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (катнашу өлешләрен, оешмаларның устав капиталы (склад итеп тотылучы) пайларын) сатып алуга киткән акчаларның алыну чыганаклары турындагы белешмәләр Инспекциянең рәсми сайтында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган тәртиптә урнаштырыла, ә мондый белешмәләр Инспекциянең рәсми сайтында булмаган очракта – массакүләм мәгълүмат чараларына аларның сораулары буенча тапшырыла.

13. Әлеге Нигезләмә буенча гражданин яисә граждан хезмәткәре тарафыннан тапшырылучы белешмәләр белән эшләү вәкаләте вазыйфаи вәкаләтләренә кергән, аларны фаш итүче яисә Россия Федерациясе законнарында каралмаган максатларда кулланучы граждан хезмәткәрләре Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

14. Гражданин яисә граждан хезмәткәре тарафыннан әлеге Нигезләмә буенча тапшрылучы керемнәр турындагы, милек һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләр, һәм әлеге белешмәләрнең дөреслеген һәм

тулылыгын тикшерүнең нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат граждан хезмәткәренең шәхси эшенә теркәлә.

15. Керемнәр турында, милек һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында күрәләтә торып ялган белешмәләрне тапшыру яисә тапшырмау очрагында гражданин граждан хезмәте вазыйфасына билгеләнә алмый, ә граждан хезмәткәре граждан хезмәте вазыйфасыннан азат ителә яисә Россия Федерациясенең законнары нигезендә башка төр дициплинар җаваплылыкка тартыла.

Граждан хезмәткәрләренең үз чыгымнары турындагы белешмәләрне тапшырмавы яисә тулы булмаган күләмдә яисә дөрес булмаган көе тапшыруы, яисә хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турындагы белешмәләрне тапшырмавы яисә күрәләтә торып тулы булмаган яисә дөрес булмаган көе тапшыруы, әгәр дә мондый белешмәләрне тапшыру мәҗбүри булса, биләгән вазыйфадан азат ителүгә, билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтеннән куылуга дучар итүче хокук бозу булып санала.

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясендәге Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрне тапшыруы турындагы Нигезләмәгә
кушымта

**Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең чыгымнары турында, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында (1))**
**Белешмә**

______________________________
(дәүләт органы җитәкчесенең

______________________________
(дәүләт вазыйфасын биләүче затның)

______________________________
вазыйфасы, Ф.И.А. )

Мин, ______________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу көне)

_______________________________________________________________________,
(хезмәт урыны һәм биләгән вазыйфасы)

түбәндәге адрес буенча яшәүче ______________________________________
(яшәү урыны һәм (яки) теркәлү адресы)

_______________________________________________________________________,

20__ елның 1 гыйнварыннан 20__ елның 31 декабренә кадәрге хисап чорында,
_______________________________________________________________________
(минем, хатыным (ирем), балигъ булмаган балам тарафыннан (2))
_______________________________________________________________________
_______________________________________________________________________

_____________________________________________________________ нигезендә,
(сату-алу килешүе яисә

_______________________________________________________________________,
законда каралган хокукый милекне сатып алуга башка нигез *(3))

_______________________________________________________________________
_______________________________________________________________________

______________________________________________________________________________
(җир кишәрлеге, күчемсез милекнең башка объекты,

______________________________________________________________________________
транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (катшану өлешләре,

______________________________________________________________________________
оешмаларның устав капиталы (склад итеп тотылучы) пайлары)

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________.

_____________________________________________________сатып алынганлыгы турында хәбәр итәм.
Килешүнең суммасы ___________________________________________ сум.

Милек сатып алуга тотылган акчаларның чыганаклары булып түбәндәгеләр тора *(4):
_____________________________________________________________________________.
Әлеге белешмәне тапшыручы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең һәм аның хатынының (иренең) милек сатып алганның алдагы өч ел эчендәге гомуми керемнәре суммасы,
______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________ сум.

Әлеге белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын раслыйм.
"___"_____________ 20__ ел.
_____________________________________________________________________________
(белешмәне тапшырган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең имзасы)

Белешмәне кабул итеп алды _____________________________________________
(белешмәне кабул итеп алучы затның Ф.И.А. һәм имзасы)

*(1) Белешмә, килешүнең суммасы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең һәм аның хатынының (иренең) килешү ясалган көннең алдагы өч елы эчендәге гомуми керемнәреннән артып киткән очракта, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турындагы, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләр белән бергә тапшырыла.

*(2) әгәр дә килешү хатыны (ире) һәм (яисә) балигъ булмаган баласы тарафыннан башкарылса, хатынының (иренең) һәм (яисә) балигъ булмаган баласының фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, яшәгән урыны һәм (яисә) теркәлгән урыны күрсәтелә.

*(3) Белешмәгә хокукый милекне сатып алу килешүенең яисә башка документының күчермәсе беркетелә.

*(4) Белешмәне тапшырган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең һәм аның хатынының (иренең) (хатынының (иренең) фамилиясе, исеме, атасының исеме, яшәгән урыны һәм (яисә) теркәлгән урыны күрсәтелә) төп эш урыны буенча кереме; аталган затларның законда рөхсәт ителгән эшчәнлектән алган кереме; банклардагы һәм башка кредит оешмаларындагы кертемнәрдән алынган керем; алдагы еллардан җыелган акчалар; мирас; бүләк; заем; ипотека; милекне сатудан алынган керем; башка кредит йөкләмәләре; башкасы”.

Татарстан Республикасының Дәүләт
торак инспекциясе боерыгына
2 нче кушымта
«31» 10 2013 ел.
№ 149

**Инспекциянең, аларга билгеләнгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, һәм шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәне тапшыру мәҗбүри булган һәм шулай ук аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, һәм шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәне тапшыру мәҗбүри булган дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының Исемлеге**

1. Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе башлыгы – 1 бер.;
2. Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе башлыгы урынбасары – Татарстан Республикасының баш дәүләт торак инспекторы урынбасары – 3 бер.;
3. Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе башлыгы урынбасары – Татарстан Республикасының баш дәүләт торак инспекторы урынбасары – хокукый идарә башлыгы – 1 бер.;
4. Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе башлыгы урынбасары – зонаара торак инспекциясе башлыгы – 6 бер.;
5. Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе башлыгы урынбасары – Казан шәһәренең торак инспекциясе башлыгы – 1 бер.;
6. Казан шәһәренең торак инспекциясе башлыгы урынбасары – 1 бер.;
7. Үзәк инспекторлык бүлеге башлыгы – 1 бер.;
8. Үзәк инспекторлык бүлеге башлыгы урынбасары – 1 бер.;
9. Чаллы зонаара торак инспекциясе башлыгы урынбасары – 1 бер.;
10. Үзәк инспекторлык бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе – 4 бер.;
11. Үзәк инспекторлык бүлегенең әйдәп баручы консультанты – 3 бер.;
12. Әйдәп баручы белгеч – үзәк инспекторлык бүлеге эксперты – 1 бер.;
13. Торак фондының капиталь төзекләндерелешен контрольдә тоту бүлеге башлыгы – 1 бер.;
14. Торак фондының капиталь төзекләндерелешен контрольдә тоту бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе – 1 бер.;
15. Торак фондының капиталь төзекләндерелешен контрольдә тоту бүлегенең әйдәп баручы консультанты – 1 бер.;
16. Әйдәп баручы белгеч - торак фондының капиталь төзекләндерелешен контрольдә тоту бүлеге эксперты – 4 бер.;
17. ТКХ өчен түләүләрнең нигезлелеген тикшерү бүлеге башлыгы – 1 бер.;

18. ТКХ өчен түләүләрнең нигезлелеген тикшерү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе – 2 бер.;
19. ТКХ өчен түләүләрнең нигезлелеген тикшерү бүлегенең әйдәп баручы консультанты – 2 бер.;
20. Хокукый идарәнең юридик бүлеге башлыгы – 1 бер.;
21. Хокукый идарәнең юридик бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе – 2 бер.;
22. Хокукый идарәнең юридик бүлегенең әйдәп баручы консультанты – 1 бер.;
23. Әйдәп баручы белгеч – хокукый идарәнең юридик бүлегенең эксперты – 2 бер.;
24. Хокукый идарәнең административ практика бүлеге башлыгы – 1 бер.;
25. Әйдәп баручы белгеч – хокукый идарәнең административ практика бүлеге эксперты – 2 бер.;
26. Бухгалтер исәбе һәм хисабы бүлеге башлыгы – 1 бер.;
27. Бухгалтер исәбе һәм хисабы бүлегенең 1 нче разрядлы өлкән белгече – 2 бер.;
28. Җыелма анализ һәм автоматлаштыру бүлеге башлыгы – 1 бер.;
29. Җыелма анализ һәм автоматлаштыру бүлегенең әйдәп баручы белгече – 1 бер.;
30. Җыелма анализ һәм автоматлаштыру бүлегенең 1 нче разрядлы өлкән белгече – 1 бер.;
31. Җыелма анализ һәм автоматлаштыру бүлегенең 1 нче разрядлы белгече – 1 бер.;
32. Кадрлар бүлеге башлыгы – 1 бер.;
33. Кадрлар бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе – 1 бер.;
34. Әйдәп баручы белгеч – кадрлар бүлеге эксперты – 1 бер.;
35. Гражданнарның мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлеге башлыгы – 1 бер.;
36. Гражданнарның мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе – 1 бер.;
37. Әйдәп баручы белгеч – гражданнарның мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлеге эксперты – 3 бер.;
38. Гражданнарның мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлегенең 1 нче разрядлы белгече – 1 бер.;
39. Гомуми бүлек башлыгы – 1 бер.;
40. Казан шәһәренең торак инспекциясе консультанты – 6 бер.;
41. Зонаара торак инспекциясе консультанты – 14 бер.;
42. Әйдәп баручы белгеч – Казан шәһәренең торак инспекциясе эксперты – 17 бер.;
43. Әйдәп баручы белгеч – зонаара торак инспекциясе эксперты – 20 бер.;
44. Казан шәһәренең торак инспекциясенең 1 нче разрядлы белгече – 3 бер.;
45. Зонаара торак инспекциясенең 1 нче разрядлы белгече – 8 бер.

---

Дәүләт граждан хезмәтенең БАРЛЫК вазыйфалары – 130 бер.